ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» Федераль законны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында гамәлгә ашыру хакында

«Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» 1996 елның 15 августындагы 114-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 пунктчасының өченче абзацы, «Аерым категориядәге затларның Россия Федерациясеннән чыгу турында Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенә (территориаль иминлек органына) һәм Россия Федерациясе тышкы разведка хезмәтенә алдан хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 20 маендагы 429 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар кабул итү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 27 сентябре
№ 72-VII ДС

2024 елның «27» сентябрендәге
72-VII ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карары белән
расланды

Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар кабул итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» 1996 елның 15 августындагы 114-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» Федераль закон) нигезендә эшләнде һәм аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының (алга таба – Дәүләт Советы депутаты) Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар кабул итүне җайга сала.

2. Әгәр Дәүләт Советы депутаты депутат вәкаләтләрен башкаруга бәйле рәвештә аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булса, аның Россия Федерациясеннән чыгу хокукы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе (алга таба – Дәүләт Советы Рәисе) карары белән вакытлыча чикләнергә мөмкин.

3. Депутат вәкаләтләрен башкаруга бәйле рәвештә аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Дәүләт Советы депутаты тиздән Россия Федерациясеннән чыгуы турында әлеге чыгу көненә кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, ә әлеге Тәртипнең 11 пунктында каралган очракларда – кичекмәстән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының яшеренлек режимын тәэмин итү функциясен башкаручы структур бүлекчәсенә (алга таба – Дәүләт Советы Аппаратының яшеренлек режимын тәэмин итү бүлекчәсе) әлеге Тәртипкә кушымтада каралган рәвештә Россия Федерациясеннән чыгу турында хәбәрнамә җибәрү (тапшыру) юлы белән Дәүләт Советы Рәисенә язмача хәбәр итәргә тиеш.

4. Дәүләт Советы Аппаратының яшеренлек режимын тәэмин итү бүлекчәсе Дәүләт Советы депутатыннан Россия Федерациясеннән чыгу турында хәбәрнамә алынган көннән алып өч эш көне эчендә Дәүләт Советы Рәисенә Дәүләт Советы депутатының аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булуы хакында 2004 елның 5 гыйнварындагы 3-1 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән

расланган Россия Федерациясендә яшеренлек режимын тәэмин итү буенча инструкциядә (алга таба – Инструкция) билгеләнгән рәвештә бәяләмә җибәрә.

5. Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар кабул иткәндә, Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан Дәүләт Советы депутаты депутат вәкаләтләрен башкару чорында хәбәрдар булган белешмәләрнең характеры, Россия Федерациясеннән чыгуның максаты һәм мондый чикләү кулланунының зарурлыгы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирүче башка хәлләрнең булуы исәпкә алына. Дәүләт Советы Рәисе аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында Дәүләт Советы депутатының аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булуы хакында бәяләмә кергән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча карар кабул итә, ул Инструкциядә билгеләнгән рәвештә рәсмиләштерелә.

6. Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар Дәүләт Советы Аппаратының яшеренлек режимын тәэмин итү бүлекчәсе тарафыннан рәсмиләштерелә. Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан имзаланган карар Дәүләт Советы мөһере белән таныклана.

7. Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар кабул ителгән очракта, Дәүләт Советы Рәисе Дәүләт Советы исеменнән, мондый карар кабул ителгән көннән соң килүче өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Дәүләт Советы депутатына яисә аның законлы вәкиленә әлеге чикләүнең нигезе һәм срогы, бу карарның датасы һәм теркәү номеры, Дәүләт Советының тулы исеме һәм адресы күрсәтелгән хәбәрнамә тапшыра (җибәрә), йә Дәүләт Советы Аппаратының яшеренлек режимын тәэмин итү бүлекчәсе Дәүләт Советы исеменнән әлеге Дәүләт Советы депутатын яисә аның законлы вәкилен, кул куйдырып, аңа карата Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында кабул ителгән карар белән таныштыра. Дәүләт Советы депутаты Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турындагы карар белән танышудан баш тарткан очракта, танышудан баш тарту турында акт төзелә.

8. Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Дәүләт Советы депутатының Россия

Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карарга федераль законнарда каралган тәртиптә дәгъва белдерергә мөмкин.

9. Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар кабул ителгән очракта, депутатның Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданы шәхесен таныклый торган Россия Федерациясе гражданы паспорты (паспортлары) Дәүләт Советы депутатына Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турындагы карарны җиткергән көннән алып биш эш көне эчендә Дәүләт Советы Аппаратының яшеренлек режимын тәэмин итү бүлекчәсенә бу чикләү срогы беткәнче йә аның (аларның) гамәлдә булу срогы чыкканчы саклауга тапшырылырга тиеш.

10. «Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү срогы аеруча мөһим белешмәләр яисә тулысынча яшерен белешмәләр белән соңгы тапкыр танышкан көннән алып биш елдан да артыграк була алмый. Бу срок «Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә озайтылырга мөмкин.

11. Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар кабул ителгән Дәүләт Советы депутатына, Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгуы таләп ителә торган документаль расланган түбәндәге хәлләр барлыкка килгән очракта, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан Россия Федерациясеннән кыска вакытлы чыгу рөхсәт ителергә мөмкин:

а) аның үзенә ашыгыч дәвалану йә аның якын туганына ашыгыч дәвалану яисә аны мондый дәвалануга озата бару зарурлыгы, башка якын туганнары озата бару мөмкинлеге булмаганда;

б) Россия Федерациясе территориясеннән читтә булган якын туганының гомеренә яисә сәламәтлегенә куркыныч янау;

в) Россия Федерациясе территориясеннән читтә булган якын туганы вафат булу;

г) чит дәүләт законнары нигезендә варислык кабул итүгә бәйле юридик әһәмияткә ия гамәлләр кылганда шәхси катнашу зарурлыгы.

12. Дәүләт Советы депутатының Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләүгә бәйле әлеге Тәртиптә каралмаган башка мәсьәләләр «Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» Федераль закон нигезендә җайга салына.

Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә
тулысынча яшерен белешмәләрдән
хәбәрдар Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатының
Россия Федерациясеннән чыгу
хокукын чикләү турында карар
кабул итү тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
______________________________

Россия Федерациясеннән чыгу турында
хәбәрнамә

Мин,____________________________________________________________
(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булса)

________________________________________________________________________________,
туган көнем _____ елның «___» _____________, паспорт сериясе _____________
№______________, ____________________________________________
(паспорт бирелү датасы һәм биргән орган)

______________________________________________________ тарафыннан бирелде,
2024 елның 20 маендагы 429 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган Аерым категориядәге затларның Россия Федерациясеннән чыгу турында Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенә (территориаль иминлек органына) һәм Россия Федерациясе тышкы разведка хезмәтенә алдан хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәнең 6 пункты нигезендә Сезгә үземнең ____________________________________________
(дәүләт яисә дәүләтләр исеме, транзит дәүләтләрне дә кертеп)

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

______баруым турында хәбәр итәм.

Россия Федерациясе территориясе чикләреннән читтә булу планлаштырыла торган срок ____________________________________________.

Россия Федерациясеннән чыгуның максаты ________________________

________________________________________________________________________.

Россия Федерациясеннән чыгу өчен файдаланылачак транспорт төре________________________________________________________________.

Россия Федерациясеннән читтә булу адресы_________________________.

20___ елның «____» __________________ ___________________________.

(хәбәрнамә биргән затның имзасы)